ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 15 апреле** **Чистай шәһәре** **№ 213**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 27 июнендәге 331 номерлы
карары белән расланган ана (гаилә) капиталы
чараларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла
торган ИЖС объектын төзү (реконструкцияләү)
буенча төп эшләр башкаруны раслый торган
документ бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең Административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында,

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 июнендәге 331 номерлы карары белән расланган ана (гаилә) капиталы чараларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган ИЖС объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслый торган документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегенең 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законы нигезендә әлеге объектларга инвалидлар өчен керү мөмкинлеген | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм кирәкле янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә мәгълүмат стендлары белән документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул | |

| | | |
|---|---|---|
| тәэмин итүгә, әлеге хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм бизәүгә карата таләпләр | исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-колясkalардан һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларга бина, бүлмәләр һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану шартлары тәэмин итү чаралары гамәлгә ашырыла, шул исәптән:<br>- биналарга һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү өчен шартлар;<br>- элемтә һәм мәгълүмат чараларыннан тоткарлыксыз файдалану өчен шартлар;<br>- объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-коляска кулланып, мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренә ия булган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, бинага, бүлмәләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне тиешенчә урнаштыру;<br>-инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә рөхсәт;<br>- бинага һәм бүлмәгә үткәрүче этне кертү, аны махсус укытуны раслый торган һәм формасы буенча бирелә торган һәм дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, халыкны социаль яклау өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә бирелүче документ булганда; | |

| | | |
|---|---|---|
| | - хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга хезмәт күрсәтү, киртәләрне җиңеп чыгу, аларга хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы башка затлар белән беррәттән ярдәм күрсәтү.» | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазифаларын башкаручы П.Б. Емельянов